**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Зур Көек торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28 октябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 28 октябрендә 15 сәгать 00 минутта уздырылган "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

- авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (насос урнаштырылган скважина бораулау, су белән тәэмин итү линиясе салу өчен материаллар сатып алу, ТР Биектау районының Зур Көек торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу җайланмасы булдыру мөмкинлеге турында килешү буенча түләү, шулай ук скважина бораулау проектын эшләүгә түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 63 (алтмыш өч) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 35 кеше, бу 55,5% ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 34 (утыз дүрт) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 1 (бер) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Зур Көек авыл җирлеге

территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә кертергә.

3. Мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын үзара салым түләүдән азат итәргә (исемлек теркәлә).

4. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (насос урнаштырылган скважина бораулау, су белән тәэмин итү линиясе салу өчен материаллар сатып алу, ТР Биектау районының Зур Көек торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу җайланмасы булдыру мөмкинлеге турында килешү буенча түләү, шулай ук скважина бораулау проектын эшләүгә түләү)

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Сафиуллин

28.10.2022 № 1 гражданнар
җыенына кушымта

Зур Көек авылы буенча мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары исемлеге

| № | ФИО | Туган елы | Адресы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мифтахов Айрат Булатович | 1978 | Зур Көек авылы, Үзәк урам, 21 йорт |
| 2 | Мифтахов Булат Хабриевич | 1948 | Зур Көек авылы, Үзәк урам, 21 йорт |
| 3 | Мифтахова Нажия Фатхрахмановна | 1952 | Зур Көек авылы, Үзәк урам, 21 йорт |